КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 22 июль г.Казань № 640

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдыру турында» 2008 ел, 11 июль, 488 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдыру турында» 2008 ел, 11 июль, 488 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 5 май, 296 нчы; 2016 ел, 24 май, 341 нче; 2017 ел, 20 июнь, 398 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның преамбуласында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдыру һәм алардан файдалану тәртибе турында» 1996 елның 10 ноябрендәге 1340 нчы карары» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен федераль башкарма хакимият органнарының матди ресурслары резервларын булдыру, алардан файдалану һәм аларны тулыландыру тәртибе турында» 1996 елның 10 ноябрендәге 1340 нчы карары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары номенклатурасын һәм күләмен яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин